ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2026 Олы Кайбыч ав. № 224

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2026 елның 19 гыйнварындагы 7 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның 20 апрелендәге 211 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

кушымтаның 15.6 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын булдыру, җиһазлау һәм әзерләү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча дәүләт системасының кирәкле көчләрен җиһазлау һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының эшләр идарәчесе Д.А.Бәдертдиновага йөкләргә.

Җитәкче А.Н.Макаров